# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ
# К А Р А Р

| 21.11.2016 | | №102 |
|---|---|---|

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссияләренең беренче нөсхәләре мәгълүматлары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе 2016 елның 20 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзегән, аның нигезендә, 2017 елның 19 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

" 2017 елда Урта Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләү күләме 150 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, , 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

1 - урам яктырткычлар алыштыру һәм урнаштыру; Тубән Аты ,Урта Сәрдә Кылачы

-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге. Вак таш сатып алу, юл-урам челтәренә вак таш салу: Тубән Аты ,Урта Сәрдә ,Клачы авыллары

- Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү

Урта Сәрдә авылы өчен мотопомпа сатып алу;

- Кылачы авылында урнаштыру өчен янгын савытын сатып алу;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта акчаны Урта Аты авыл җирлеге Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә” дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителде дип танырга.

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 816 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны-717, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның 87,87% ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 658(91,77%) кеше тавыш бирде, «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 59 кеше тавыш бирде, бу 8,23% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге территориясендә **2017 елның 19 ноябрендәге җирле референдум** узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга

2. " 2017 елда Урта Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләү күләме 150 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, , 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

-урам яктырткычлар алыштыру һәм урнаштыру; Түбән Аты ,Урта Сәрдә Кылачы

-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге. Вак таш сатып алу, юл-урам челтәренә вак таш салу: Түбән Аты ,Урта Сәрдә ,Клачы авыллары

- Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

Урта Сәрдә авылы өчен мотопомпа сатып алу;

- Кылачы авылында урнаштыру өчен янгын савытын сатып алу;

Экономия барлыкка килгән очракта акчаны Урта Аты авыл җирлеге Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә” дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителде дип танырга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева